**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯШЕЛ ҮЗӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН УРЫСБАГА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**18.12.2019 ел** **№204**

**Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибе турында.**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районының «Тубән Урысбага авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Тубән Урысбага авыл җирлеге Советының 2013 елның 14 ноябрендәге 138 номерлы карары(Тубән Урысбага авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 декабрендәге 171 номерлы, 2019 елның 12 ноябрендәге 200 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), белән расланган Нигезләмә нигезендәТубән Урысбага авыл жирлеге Советы карар итте:

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатында Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү турындагы расларга тәкъдим ителә торган тәртибен расларга.
2. Әлеге карар нигезләмәләре 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына бюджетлардан башлап бюджет төзегәндә, раслаганда һәм үтәлгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмати – телекоммуникация челтәрендә халыкка җиткерергә, шулай ук Түбән Урысбага авылы, Центральная урамы, 62а йорт (җирлек хакимияте бинасы), Түбән Урысбага авылы, Үзәк урамы, 63а йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча урнашкан Түбән Урысбага авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштырырга.

**Тубән Урысбага авыл жирлеге башлыгы,**
**Совет рәисе** **Х.Х.Сибгатуллин**

Тубән Урысбага авыл җирлеге
Советының 18 декабрь, 204 номерлы
карарына кушымта

Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатындаТатарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү турындагы тәртип.

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетына (алга таба-муниципаль берәмлекләр) Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен (алга таба – субсидияләр, җирлек) финанслашу максатларында бирелә:

- җирлекнең җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәүгә субсидияләр бирүгә ихтыяҗы булу-булмавы-җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча;

- Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан җиткерелгән сценар алымнар кысаларында исәпләнгән Тубән Урысбага авыл җирлеге чыгымнарыннан Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетының үз керемнәреннән артып китүе;

- Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетының өстәмә керемнәре исәбеннән акча бирү, шулай ук Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджеты счетындагы калган акчалар агымдагы финанс елы башына һәм (яки) Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджетында экономияләнгән очракта ассигнованиеләрне яңадан бүлү хисабына.;

- законнарда каралган башка очраклар.

2.Субсидияләр Тубән Урысбага авыл җирлеге Советының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

3. Муниципаль берәмлекләр бюджетларына субсидияләрне бүлү Тубән Урысбага авыл җирлеге Советының тиешле финанс елына һәм план чорына Тубән Урысбага авыл җирлеге бюджеты турында карары белән раслана.

4. Әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче-Тубән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты.

5. Субсидия бирүнең максатлары һәм шартлары авыл җирлеге башкарма комитеты һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты арасында төзелгән килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс белән тәэмин итүнең чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе;

ж) килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

7. Килешү проектын әзерләү Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

8. Килешү Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе һәм муниципаль берәмлек Башкарма комитеты тарафыннан имзалана.

9. Субсидия алу өчен муниципаль берәмлек Башкарма комитеты килешүдә билгеләнгән вакытта түбәндәге документларны Нур-лат авыл җирлеге башкарма комитетына тапшыра::

Түбән Урысбага авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирүгә гариза;

килешүдә билгеләнгән башка документлар.

10. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган субсидия күләме килешүдә билгеләнгән формула буенча бүленә.

11. Субсидияләр Түбән Урысбага авыл җирлеге бюджетыннан муниципаль берәмлекләр бюджетына Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетларына күчерелә.

12. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, тиешле акчалар Түбән Урысбага авыл җирлеге кеременә Россия Федерациясе Бюджет законнары белән билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

13. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Түбән Урысбага авыл җирлеге бюджеты керемендә кире кайтарылырга тиеш.

14. Субсидияләрнең максатчан кулланылышын закон нигезендә җирлек башкарма комитеты һәм муниципаль финанс контроле органнары контрольдә тота.